МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

___ 09.02.2022___ г. Казань № _под-206/22

Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының 2015 елның 1 июнендәге 6536/15 номерлы «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Мәгариф һәм министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 18 ноябрендәге 906 номерлы «Татарстан Республикасы министрлыгы, Дәүләт комитеты, ведомствосы каршындагы Иҗтимагый совет турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 26 октябрендәге 54 номерлы «Татарстан Республикасы министрлыгы, Дәүләт комитеты, ведомство каршындагы Иҗтимагый совет турындагы типлаштырылган нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә к а р а р б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 1 июнендәге 6536/15 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә (14.09.2015 под-9277/15 номерлы, 06.06.2016 под-1115/16 номерлы, 17.01.2018 под-69/18 номерлы, 20.08.2018 под-1226/18 номерлы, 23.05.2009 под-845/19 номерлы, 25.11.2021 под-1536/21 номерлы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән), түбәндәге үзгәрешләр:

6.6 пунктның икенче абзацында күрсәтелгән тәкъдим «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнелә торган биш көнлек срокка» сүзләрен өстәргә;

6.7 пунктның икенче абзацында күрсәтелгән тәкъдим «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнелә торган биш көнлек срокка» сүзләрен өстәргә;

6.8 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән тәкъдим «әлеге пунктның беренче абзацында күрсәтелгән тәкъдим алынган көннән алып, эш көннәрендә исәпләнелә торган биш көнлек срокка» сүзләрен өстәргә.

2. Юридик бүлеккә (Е.С. Борисова), боерык кабул ителгән көннән алып, өч көн эчендә аны Татарстан Республикасы юстиция Министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары С.Р. Андреевка йөкләргә.

Министр И.Г. Һадиуллин